ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
ТЕЛӘНЧЕ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“03” ноябрь 2020 ел Теләнче Тамак авылы №11

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлегенең Теләнче Тамак авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Теләнче Тамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 17 ноябренә 14.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авылы Колхоз, Кызыл армия, Тукай, Кооператив урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Теләнче Тамак авылы , Кызыл армия урамы , 21а йорт янында билгеләргә.

2. 2019 елның 18 ноябренә 14.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авылы Тау як, Совет, И. Шакиров, Мәктәп, Балалар бакчасы, Мәктәп тыкырыгы урамнарында, Татарстан урамынын 3-55 йортлары, үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Теләнче Тамак авылы, Татарстан урамы, 19 йортта билгеләргә.

3. 2019 елның 19 ноябренә 14.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авылы Сельхозтехника, Подстания, Хастаханә, Яшьләр, Яңа урамнарында, Татарстан урамынын 1 һәм 2 йортларында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Теләнче Тамак авылы, Сельхозтехника урамы, 2 йорт янында билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, Теләнче Тамак авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Теләнче Тамак авыл җирлегенең Теләнче Тамак авылы территориясендә 2021 елда балигъ булган, Теләнче Тамак авыл җирлегенең Теләнче Тамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- юлларны ремонтлау;
- санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү
- иске зират коймаларын тоу өчен материал алу һәм урнаштыру

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

6. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

8. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
9. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Нәҗметдинов